КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 сентябрь г.Казань № 839

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга, шулай ук оешмалар бетерелүгә (физик затлар эшчәнлекләрен, вәкаләтләрен туктатуга) бәйле рәвештә эштән азат ителгән затларга дәүләт пособиеләренең аерым төрләрен түләүгә субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1102 нче карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан вакытлыча эшкә яраксыз булу очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган затларга, шулай ук оешмалар бетерелүгә (физик затлар эшчәнлекләрен, вәкаләтләрен туктатуга) бәйле рәвештә эштән азат ителгән затларга дәүләт пособиеләренең аерым төрләрен түләүгә субвенцияләрне тоту кагыйдәләренә, 7 нче пунктта «, агымдагы финанс елының 15 октябреннән дә соңга калмыйча,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Беренче бала туугa (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 15 март, 154 нче карары белән (Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 2 июль, 535 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Беренче бала туу га (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә, айлык түләүне билгеләү һәм гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тоту кагыйдәләренә, 10 нчы пунктта «, агымдагы финанс елының 15 октябреннән дә соңга калмыйча,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин